ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
ШИЛНӘБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**КАРАР**

“30” сентябрь 2022 ел Шилнәбаш авылы №1

**“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлегенең Тогаево авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Шилнәбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлегенең Тогаево авылында 2022 елның 12 октябрендә 17.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Шилнәбаш авыл җирлегенең Тогаево авылы территориясендә 2023 елда балигъ булган, Шилнәбаш авыл җирлегенең Тогаево авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

- балалар мәйданчыгын төзекләндерү (койма алу һәм урнаштыру, Балалар уен әйберләрен сатып алу һәм урнаштыру);

“ӘЙЕ” “ЮК”.

3. Татарстан Республикасы, Тукай районы, Тогаево авылы, Центральная урамы, 15 йорт адресы буенча гражданнар җыенын үткәрергә.
4. Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
7. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Шилнәбаш
авыл җирлеге Башлыгы О.А. Гончарова